РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
12.02.2026

КАРАР
№4

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 12.11.2025 №9 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 29 һәм 65 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 29.12.2025 ел, №548-ФЗ Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 12.11.2025 ел, №9 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 1.9.1 пунктның 5 пунктчасында «аларның вәкилләре,» сүзләреннән соң «үз-үзен җайга салучы оешма вәкилләре, әгәр контрольдә тотылучы зат өчен үз-үзен җайга салучы оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru  Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы

Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/kibiachi адреслары буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы А.К.Сафин